КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 апрель г.Казань № 329

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы, 2018 ел, 7 май, 327 нче, 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә, 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.1. Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрен оештыру һәм эшләтү өлкәсендә идарә итү, Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару, төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм куллану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге, үсемлекләр дөньясы объектларын саклау өлкәсендә төбәк экологик күзәтчелеге, үсемлекләр дөньясыннан файдалану өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып тора, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында көндәшлекне үстерү максатларының һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итү буенча, шулай ук Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган, шул исәптән хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, федераль дәүләт күзәтүе һәм куллануны җайга

салу, эчке су объектларында су биологик ресурсларын саклау буенча вәкаләтләр башкара.

Дәүләт комитетының кыскартылган исеме – Биоресурслар буенча ТР дәүләт комитеты.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин